МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ
И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ
РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** Казан шәһәре **БОЕРЫК**

06.08.2018 789-п

**«Эгида +» ҖЧҖ су алу скважиналарының санитар саклык зонасын оештыру проектын раслау турында**

Россия Федерациясе Су кодексы, «Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы Федераль закон, «Су белән тәэмин итү чыганакларының һәм эчә торган су үткәргечләренең санитар саклык зоналары. СанПиН 2.1.4.1110-02» санитария кагыйдәләре һәм нормалары, «Җир асты суларын пычранудан саклауга карата гигиена таләпләре. СП 2.1.5.1059-01» санитария кагыйдәләре, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 325 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә эчә торган су һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү өчен кулланыла торган су объектларының санитар саклык зоналары проектларын раслау тәртибе турында» 2012 елның 29 февралендәге 177 номерлы карары нигезендә һәм җир асты байлыкларыннан файдалануга 2010 елның 25 февралендәге ТАТ 01345 ВЭ лицензияне, Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең 2015 елның 31 декабрендәге проектның дәүләт санитар-эпидемиологик кагыйдәләргә һәм нормаларга туры килү турында №16.11.11.000.Т.002790.12.15 санитар-эпидемиологик бәяләмәсен исәпкә алып, шулай ук «Эгида+» ҖЧҖ тарафыннан тәкъдим ителгән «Эгида+» ҖЧҖ су алу скважиналарының санитар саклык зонасын оештыру проекты нигезендә

**БОЕРЫК БИРӘМ:**

1. «Эгида +» ҖЧҖ су алу скважиналарының санитар саклык зонасын оештыру проектын (алга таба – Проект) расларга.

2. 1 нче кушымта нигезендә «Эгида+» ҖЧҖ су алу скважиналарының санитар саклык зонасы чикләрен билгеләргә.

3. 2 нче кушымта нигезендә «Эгида+» су алу скважиналарының санитар саклык зоналары чикләрендә территорияләрдән хуҗалык өчен файдалану режимын билгеләргә.

4. Проект күчермәсен Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына җибәрергә.

5. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенә түбәндәге чараларны үткәрү турында тәкъдим итәргә:

«Эгида+» ҖЧҖ су алу скважиналарында санитар саклык зоналарының чикләре, су алу корылмасының санитар саклык зоналары чикләрендә территорияләрдән хуҗалыкта файдалану кагыйдәләре һәм режимнары турында халыкка хәбәр итүне оештыру турында;

территорияләр үсешенең территориаль комплекс схемаларын, функциональ зоналарга бүлү схемаларын, җир корылышы схемаларын, районнарны планлаштыру проектларын һәм генераль планнарны эшләгәндә Проектны исәпкә алуны оештыру турында.

Министр в.б. Ф.Ф. Шакиров

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигать
ресурслары министрлыгының
06.08.2018 № 789-п боерыгына
1 нче кушымта

**«Эгида +» ҖЧҖ су алу скважиналарының санитар саклык зоналары чикләре**

«Эгида +» ҖЧҖ су алу корылмасы Казан шәһәренең көнбатыш өлешендә Казан шәһәре, Киров районы, Калинино поселогы, 2 нче Красноборская урамы адресы буенча урнашкан. Су алу корылмасы предприятие территориясенең көнчыгыш өлешендә урнашкан ике скважинадан тора. Скважиналар бер-берсеннән 10 метр ераклыкта урнашкан.

Су алу скважиналарының географик координатлары:

№1 скв. резервта тора: т.к. $55^0 48'58''$, к.о. $48^0 56'31''$;

№2 скв. эшли торган: т.к. $55^0 48'58''$, к.о. $48^0 56'32''$.

Санитар саклык зоналары өч пояс составына оештырыла: беренче пояс (катгый режимлы) су алу корылмасы урнашкан территорияне, барлык суүткәргеч корылмаларының һәм су үткәрү каналы мәйданчыкларын үз эченә ала. Икенче һәм өченче пояслар (чикләүләр пояслары) су белән тәэмин итү чыганагы пычрануын кисәтү өчен билгеләнгән территорияне үз эченә ала.

Санитар саклык зонасының I поясы

«Эгида +» ҖЧҖ җир астыннан су алу корылмасының санитар саклык зонасындагы беренче поясы чикләре скважиналар авызыннан 15 метрлы радиус белән билгеләнә.

Санитар саклык зонасының II поясы

Әлеге су алу җайланмасының санитар саклык зонасындагы икенче поясы җир асты сулары агымы буенча сузылган эллипстан гыйбарәт.

Су алу корылмасының санитар саклык зонасында икенче пояснның гомуми озынлыгы $L$=171,6 метр, шул исәптән җир асты сулары агымы буенча аска таба $r$ = 78 метр, җир асты сулары агымы буенча өскә таба $R$ = 93,6 метр.

Санитар саклык зонасының икенче поясының иң зур киңлеге 2$d$ 28,2 метрга тигез.

Санитар саклык зонасының III поясы

«Эгида+» ҖЧҖ җир астыннан су алу корылмасының санитар саклык зонасындагы өченче поясы җир асты сулары агымы буенча сузылган эллипстан гыйбарәт.

Су алу корылмасының санитар саклык зонасында икенче пояснның гомуми озынлыгы $L$=788 метр, шул исәптән җир асты сулары агымы буенча аска таба $r$ = 148 метр, җир асты сулары агымы буенча өскә таба $R$ = 640 метр.

Үзәк өлештә санитар саклык зонасының 2$d$ III поясының киңлеге – 307 метр.

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигать ресурслары
министрлыгының 06.08.2018 № 789-п
боерыгына 2 нче кушымта

**«Эгида+» ҖЧҖ су алу скважиналарының санитар саклык зоналары чикләрендә территорияләрдән хуҗалыкта файдалану режимы**

1. Санитар саклык зоналарының беренче поясы

1.1. Санитар саклык зонасындагы беренче пояс территориясе өслек агымын аннан читкә агызып җибәрү өчен планлаштырылган, яшелләндерелгән, коймалап алынган һәм сак белән тәэмин ителгән булырга тиеш. Корылмаларга бара торган юллар каты өслекле булырга тиеш.

1.2. Санитар саклык зонасындагы беренче пояс территориясендә түбәндәгеләр рөхсәт ителми: биек кәүсәле агачлар утырту, төзелешнең су үткәрү корылмаларын эксплуатацияләү, үзгәртеп кору һәм киңәйтүгә турыдан-туры кагылышы булмаган барлык төрләре, шул исәптән төрле билгеләнештәге торбаүткәргечләр салу, торак һәм хуҗалык-көнкүреш биналары урнаштыру, кешеләрне яшәтү, агулы химикатлар һәм ашламалар куллану.

1.3. Санитар саклык зонасының беренче поясы территориясендәге биналар ташландык суларны көнкүреш яки эшчәнлек канализациясенең иң якын системасына яки санитар саклык зонасындагы беренче пояcтан читтә икенче пояс территориясендәге санитар режимны исәпкә алып урнаштырылган җирле чистарту корылмалары станцияләренә агыза торган канализация белән җиһазландырылырга тиеш.

Искәрмәле очракларда, канализация булмаса, санитар саклык зонасының беренче поясы территориясе пычрануга юл куймый торган, нәҗесләрне һәм көнкүреш калдыкларын кабул итү өчен су үткәрми торган корылмалар төзелергә тиеш.

1.4. Санитар саклык зонасының беренче поясында урнашкан су үткәрү корылмалары скважина очлыклары һәм скважина авызлары, резервуарларның люклары һәм агызу торбалары һәм насосларга су тутыру җайланмалары пычрану мөмкинлеген калдырмауны исәпкә алып җиһазландырылырга тиеш.

1.5. Су алу корылмаларының барысы да су алу корылмасын проектлаганда һәм санитар саклык зонасы чикләрен нигезләгәндә каралган проект җитештерүчәнлегендәге су алу корылмасын эксплуатацияләгәндә фактик дебитның туры килүенә системалы тикшерү уздыру аппаратурасы белән җиһазландырылырга тиеш.

2. Икенче һәм өченче пояслар буенча чаралар

2.1. Сулы горизонтларны пычрату ихтималлыгы өлешендә куркыныч

тудыра торган барлык искергән, эшләми торган, җитешсезлекләре булган яки дөрес эксплуатацияләнми торган скважиналарны ачыклау, цементлау яки торгызу.

2.2. Яңа скважиналарны бораулау һәм яңа төзелешнең туфрак катламын бозуга бәйле эшләре дәүләт санитар-эпидемиология күзәтчелеге үзәге белән мәҗбүри килештереп гамәлгә ашырыла.

2.3. Яраксызланган суларны җир асты су горизонтларына агызуны, каты калдыкларны җир астында урнаштыруны һәм җир асты байлыклары белән эшләр башкаруны тыю.

2.4. Ягулык-майлау материаллары, агулы химикатлар һәм минерал ашламалар складлары, сәнәгый агынтыларны туплау, шлам саклау җайланмаларын һәм җир асты суларын химик пычрату куркынычы белән аңлатыла торган башка объектларны урнаштыруны тыю.

Мондый объектларны санитар саклык зоналарының өченче поясы чикләрендә урнаштыру бары тик якланган җир асты суларыннан файдаланганда гына, сулы горизонты саклау буенча махсус чаралар үтәү шарты белән, геологик контрольлек органнары бәяләмәсен исәпкә алып бирелгән дәүләт санитар-эпидемиология күзәтчелеге үзәгенең санитар-эпидемиология бәяләмәсе булган очракта гына рөхсәт ителә.

2.5. Файдаланыла торган сулы горизонтка турыдан-туры гидрологик бәйләнеше булган җир өсте суларын санитар саклаганда җир өсте суларын саклауга карата гигиена таләпләре нигезендә кирәкле чараларны үз вакытында башкару.